| ГЛАВА<br>САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.10.2025 Сарсак-Умга авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Умга торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Омга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Умга торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 21 октябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Умга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән

(I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

-  Сарсак-Умга торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Фермер, Логовая, Кызылармеец урамнарындагы чокырларны ремонтлау өчен  таш сатып алу һәм җәю,  автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су  башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары сатып алу, сууткәргеч челтәрен ремонтлау һәм Сарсак-Умга торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (үләннәрне чаптыру, авария хәлендәге һәм корыган  агач-куакларны кисү, торак пункт урамнарын кардан чистарту, мәдәният йортының җылыту казаны урнашкан бинаның түбәсен ремонтлау, трактор өчен асылма җиһазлар (ротор чапкычы) сатып алу һәм территорияне төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар янындагы территорияне төзекләндерү (мемориаль такта һәм һәйкәл ясау һәм урнаштыру).

“КИЛЕШӘМ” “КАРШЫ”

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Сарсак-Умга авылы, Киров мәйданы, 15 йорт, авыл мәдәният  сарае адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең  Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Т.С. Николаева

Совет Сарсак-Омгинского сельского поселения
Сарсак-Умга авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002565